| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.08.2014 Казан ш. № 1618-р

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклык зонасы чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 статьясына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында" 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Граница» Кадастр үзәге» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 425 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 1,7 кв.км.лы территорияне тәшкил иткән ЭПУ «Нижнекамскгаз»ның әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлгеч челтәрләренең саклык зонасы чикләрен 03.06.2013 - 12.12.2013 аралыгында «Граница» Кадастр үзәге» ҖЧҖ башкарган һәм 2013 елның 31 декабрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты

объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп расларга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зоналары турында белешмәне Күчемсез милек дәүләт кадастрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналарына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә йөкләүләрне Күчемсез милек хокуклары һәм аның белән алыш-биреш итү бердәм дәүләт реестрында регистрацияләү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны Татарстан Республикасы буенча “Росреестр федераль кадастр палатасы” филиалына юлларга, шулай ук, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары Демидов Сергей Анатольевичка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**